ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.08.2026 1271

Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә рөхсәтсез (үз белдеге белән) төзелгән объектларны күчерү (демонтажлау) турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 225-227 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә үз белдеге белән билгеләнгән һәм (яисә) законсыз урнашкан күчемле мөлкәтне ачыклау һәм сүтү тәртибе турында» 2020 елның 15 июнендәге 480 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Казан урамы, 29 нчы йорт адресы буенча урнашкан, 16:47:011206:333 - кадастр номерлы җир кишәрлегенең бер өлешендә рөхсәтсез (үз белдеге белән) төзелгән объектны (гаражны) күчерү (демонтажлау) срогын, әлеге мәгълүматны Алабуга муниципаль районы сайтында урнаштырган һәм «Новая Кама» газетасында бастырылган көннән 10 көн тәшкил итә дип билгеләргә. Рөхсәтсез объектны демонтажлау һәм күчерү срогы «Новая Кама» газетасында рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә.
2. Әлеге карар Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзекләндерү һәм инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы

ЕМСЭД
Республики Татарстан
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 7C878CC2715BCC42F14A435C46E05934
Владелец: Томилин Андрей Александрович
Действителен с 27-08-2026 до 20-11-2027

А.А. Томилин